**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 мартындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителү белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты указларына кушымта нигезендә исемлек буенча үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 16 апрель
№ ПУ-231

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 16 » апрелендәге
ПУ- 231 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында» 2004 елның 27 мартындагы ПУ-290 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы, 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы һәм 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

а) 1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында материалларга җәмәгать бәяләмәсе уздыру һәм казанышларны дәүләт һәм җәмәгать тануын белдерүнең иң югары формасына объектив якын килүне тәэмин итү, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә үтенечнамәләрне карап тикшерү, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Президентының рәхмәт сүзе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәхмәт сүзе һәм «Хезмәт ветераны» исемен тапшыруга хокук бирүче Россия Федерациясе ведомство бүләкләре белән бүләкләү белән бәйле вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында оештырылды.»;

б) 3 пунктта:

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентына кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне бәяли һәм бүләкләнүченең казанышларын исәпкә алып, үтенечнамәдә күрсәтелгән бүләкләүнең төрен үзгәртергә яисә кире кагуның сәбәбен нигезләп, бүләкләүгә тәкъдим итүне кире кагарга хокуклы;

бүләкләү мөмкинлеге, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге алуга хокукны торгызу, Татарстан Республикасы дәүләт бүләгеннән мәхрүм итү турында бәяләмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре

белән бүләкләү турында, Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында указы үз көчен югалткан дип тану турында (указга үзгәреш кертү турында) тиешле дәүләт актлары проектларын әзерләүгә бәяләмәләр бирә;»;

алтынчы абзацта «дәүләт бүләкләре мәсьәләләре буенча» сүзләрен «Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентына бирелгән Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турындагы тәкъдимнәрне алдан карый һәм карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Президентына бүләкләүне хуплау турында тәкъдимнәр бирә яисә аларны кире кага. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында каралган җитәрлек нигезләр булган очракта, Комиссия Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән затны Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү өчен тиешле тәкъдимне Татарстан Республикасы Президентына кертә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда орденнар, орден медале, медальләр һәм мактаулы исемнәргә күкрәк билгеләре дубликатларын бирү турында карар кабул итә»;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда Татарстан Республикасының үзгәртеп корылган ( яңа төзелгән) муниципаль берәмлегенең дәүләт бүләген үзендә калдыру, бүләкне бүләкләнгән оешманың хокукый варисында калдыру, шулай ук дәүләт бүләген саклау һәм экспозициягә кую өчен дәүләт яисә муниципаль музейга тапшыру турында карарлар кабул итә;

Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләү системасын камилләштерү мәсьәләләрен карап тикшерә;

Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре белән бүләкләү, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Президентының рәхмәт сүзе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәхмәт сүзе һәм «Хезмәт ветераны» исемен тапшыруга хокук бирүче Россия Федерациясе ведомство бүләкләре белән бүләкләү турындагы Татарстан Республикасы Президентына бирелгән документларны бәяли һәм бүләкләү турындагы документларны хуплау яисә кире кагу турында тәкъдимнәрне, мондый тәкъдимнәрне нигезләп, Татарстан Республикасы Президентына бирә.»;

в) 7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Комиссия утырышларында дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, хезмәт коллективлары вәкилләре, галимнәр һәм белгечләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.»;

г) 8 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә таныклыклар формаларын (үрнәкләрен) һәм бүләкләү кәгазе формаларын раслау турында» 2010 елның 22 июнендәге ПУ-396 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-875 номерлы һәм 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән):

а) 1 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә таныклыклар формалары (үрнәкләре) (1, $1^1$, $1^2$ һәм 2 нче кушымталар);

бүләкләү кәгазе формалары (3, $3^1$ һәм 4 нче кушымталар).»;

б) әлеге Исемлеккә 1 нче кушымта нигезендә $1^2$ нче кушымта өстәргә;

в) әлеге Исемлеккә 2 нче кушымта нигезендә $3^1$ нче кушымта өстәргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне карау хакында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-875 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибендә:

а) 1 пунктның беренче абзацында «(алга таба – гражданнар),» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (алга таба – муниципаль берәмлекләр),» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле икенче яңа абзац өстәргә:

«Муниципаль берәмлекләрне бүләкләү турында үтенечнамәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бирә.»;

икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

в) 4 пунктның беренче абзацында «(гражданны бүләкләү турында үтенечнамә биргәндә)» сүзләреннән соң «, $1^1$ нче кушымтада (муниципаль берәмлекне бүләкләү турында үтенечнамә биргәндә)» сүзләрен өстәргә;

г) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үтенечнамәне карау «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда туктатыла.»;

д) 7 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итүне кире кагу турында» сүзләрен «Үтенечнамәне карауны туктату турында» сүзләренә алмаштырырга»;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итүне кире кагу» сүзләрен «үтенечнамәне карау туктатылу» сүзләренә алмаштырырга;

е) 1 нче кушымтаның 4 пунктында «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе» сүзләренә алмаштырырга;

ж) әлеге Исемлеккә 3 нче кушымта нигезендә $1^1$ нче кушымта өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 июнендәге ПУ-424 номерлы Указында:

а) 2 пунктта «бүләкләнүчеләргә» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә» сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктта «бүләкләнүчеләргә» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә» сүзләрен өстәргә;

в) Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турындагы Нигезләмәдә:

1 пунктта «(алга таба – гражданнар),» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә (алга таба – муниципаль берәмлекләргә),» сүзләрен өстәргә;

6 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле тугызынчы яңа абзац өстәргә:

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале;»;

тугызынчы – ундүртенче абзацларны тиешенчә унынчы – унбишенче абзацлар дип санарга;

7 пунктта:

беренче абзацта «бүләкләнүчеләргә» сүзләреннән соң «муниципаль берәмлекләргә, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле дүртенче һәм бишенче яңа абзацлар өстәргә:

«Бүләкләнгән муниципаль берәмлеккә орден муниципаль берәмлек башлыгына яисә ул вәкаләт биргән затка, кагыйдә буларак, бүләкләнгән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышында тапшырыла.

Орден алу өчен муниципаль берәмлек башлыгы яисә ул вәкаләт биргән зат чакырыла, алар белән бергә муниципаль берәмлекнең Татарстан Республикасы алдындагы казанышларына зур өлеш керткән оешмалар вәкилләре һәм башка затлар килә ала.»;

дүртенче абзацны алтынчы абзац дип санарга һәм «Орден» сүзеннән соң «бүләкләнгән оешманың» сүзләрен өстәргә;

бишенче – унынчы абзацларны тиешенчә җиденче – уникенче абзацлар дип санарга;

унберенче абзацны унөченче абзац дип санарга һәм «тапшырыла» сүзеннән соң «муниципаль берәмлек башлыгына яисә ул вәкаләт биргән затка,» сүзләрен өстәргә;

уникенче абзацны ундүртенче абзац дип санарга;

9 пунктта «гражданнарга» сүзләреннән соң «, муниципаль берәмлекләргә» сүзләрен өстәргә;

1 нче кушымтада:

атамада «бүләкләнүчеләргә» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә,» сүзләрен өстәргә;

беренче абзацта «бүләкләнгән оешмаларга» сүзләрен «бүләкләнгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә, оешмаларга һәм аларның бүлекчәләренә» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче кушымтаны әлеге Исемлеккә 4 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

3 нче кушымтаны әлеге Исемлеккә 5 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаны әлеге Исемлеккә 6 нчы кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

---

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының
2010 елның 22 июнендәге
ПУ-396 номерлы Указына
$1^2$ нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләгенә таныклык формасы (үрнәге)***

Таныклык 75х105 мм һәм ачып куйгач 150х105 мм зурлыктагы куе кызыл төстәге тире тышлыклы китапчыктан гыйбарәт.

Таныклык тышлыгының алгы ягындагы өске өлешендә Татарстан Республикасы Дәүләт гербының алтын сурәте төшерелгән, аның астында алтын хәрефләр белән төшерелгән түбәндәге язу урнашкан:

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕНӘ
ТАНЫКЛЫК

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К ГОСУДАРСТВЕННОЙ
НАГРАДЕ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Таныклык тышлыгының икенче ягында нинди дә булса язу юк.

Таныклык тышлыгының эчке ягына 2 форзац беркетелә һәм аңа җеп ярдәмендә ачык зәңгәр тангир челтәр фонындагы текстлы 8 өстәмә битле бланк беркетелә.

Өстәмә битләр бланкасының беренче битендә өстә Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте урнашкан, аның астында түбәндәге язу урнаштырыла:

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕНӘ
ТАНЫКЛЫК

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К ГОСУДАРСТВЕННОЙ
НАГРАДЕ

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

№

Өстәмә битләр бланкасының икенче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

______________________________

(Татарстан Республикасы

______________________________

муниципаль берәмлеге атамасы)

______________________________

Өстәмә битләр бланкасының өченче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

______________________________

______________________________

______________________________

бүләкләнде

Бүләк №

Татарстан Республикасы
Президенты

М.У.

**(Татарстан Республикасы Президентының Ф.И.Ан.)**

*Татарстан Республикасы*
*Президенты Указы*

(Татарстан Республикасы Президенты Указы чыккан вакыт күрсәтелә)

Өстәмә битләр бланкасының дүртенче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

______________________________

(наименование муниципального

______________________________

образования Республики Татарстан)

______________________________

Өстәмә битләр бланкасының бишенче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

Награжден_

______________________________

______________________________

______________________________

Награда №

*Президент*
*Республики Татарстан*

М.П.

**(Татарстан Республикасы Президенты Ф.И.Аи)**

*Указ Президента*
*Республики Татарстан*

( Татарстан Республикасы Президенты Указы чыккан вакыт күрсәтелә)

Өстәмә битләр бланкасының алтынчы, җиденче, сигезенче битләрендә һәм арткы форзацта нинди дә булса язулар юк.

---

Искәрмә:

* Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген бүләкләү турында документ буларак файдалану өчен.».

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
Президентының
2010 елның 22 июнендәге
ПУ-396 номерлы Указына
$3^1$ нче кушымта

Татарстан Республикасы

____________________________________
(район, шәһәр)

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген
Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләүгә
**БҮЛӘКЛӘҮ КӘГАЗЕ**

______________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт бүләге атамасы)

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы__________________________

______________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге уставы нигезендә татар һәм рус телләрендә тутырыла)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

2. Оешу датасы______________________________________________________________

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең бүләкләре

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы адресы, элемтә өчен телефон______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

5. Бүләкләүгә тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең төп казанышлары______________________________________________

(Татарстан Республикасы алдындагы казанышларын, җитештерүдә, фән өлкәсендә

______________________________________________

башка казанышларын күрсәтеп, ирекле формада тутырыла)

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

Татарстан Республикасы Премьер-министры ________________________________
имзасы Ф.И.Аи

М.У.

20___ елның «_____» ____________».

__________

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
3 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
дәүләт бүләкләре белән
бүләкләү турындагы
үтенечнамәләрне карау
тәртибенә
$1^1$ нче кушымта

**Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген**
**Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә теркәп бирелә торган документлар* һәм белешмәләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) уставының аның атамасы турында рус һәм татар телләрендәге мәгълүмат китерелгән битләре күчермәсе.

2. «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе бәяләмәсе.

3. Муниципаль берәмлек Татарстан Республикасы алдында казанышларга ирешкән эшчәнлек өлкәсендә идарә функцияләрен (функциональ җайга салуны) үтәүче республика башкарма хакимият органының муниципаль берәмлекнең Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертүе турындагы белешмәләр кертелгән бәяләмәсе.

4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы биш елда һәм агымдагы елның узган айларында муниципаль берәмлекнең төп социаль-икътисадый күрсәткечләре динамикасы турында белешмәсе.

5. Татарстан Республикасы муниципаль районы вәкиллекле органының Татарстан Республикасының әлеге муниципаль районы составына керә торган муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары турында бәяләмәсе.

---

Искәрмә:

* Документлар бер ел эчендә гамәлдә дип санала.».

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
4 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
дәүләт бүләкләрен тапшыру
тәртибе турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен һәм**
**аның документларын тапшыру**
**БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________ (тапшыру урыны)

______ елның «_____» ____________ (тапшыру датасы)

Мин, ______________________________________________________________

_________________________________________________________________
(бүләкне тапшырган затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Татарстан Республикасы Президенты исеменнән түбәндәге затларга (муниципаль берәмлекләргә, оешмаларга) дәүләт бүләкләре тапшырдым:

| Т/с | Бүләкләнгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (бүләкләнгән муниципаль берәмлекнең, оешманың атамасы) | Бүләкнең төре һәм атамасы | Бүләкнең номеры* | Таныклыкның номеры* | Бүләкләү турында указның датасы һәм номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

____________________________________
(бүләкләрне тапшырган затның имзасы)

М.У.

Искәрмә:

* Татарстан Республикасы орденын, орден медален һәм медален тапшырганда тутырыла.».

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
5 нче кушымта

«Татарстан Республикасы
дәүләт бүләкләрен тапшыру
тәртибе турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләген һәм
аның документын алу турындагы
ЯЗУ**

Мин, ________________________________________________,
(Татарстан Республикасы дәүләт бүләге алган затның яисә бүләкләнгән муниципаль берәмлекнең, оешманың вазыйфасы күрсәтелгән вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

Татарстан Республикасы Президентының ______ елның «____» ___________

ПУ-_____ номерлы Указы нигезендә____________________________________

_______________________________________________________________
(бүләкнең атамасы һәм номеры, таныклыкның номеры)
_______________________________________________________________алдым.

_____ елның «_____» ______________ ____________________
(имза)».

________

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
6 нчы кушымта

«Татарстан Республикасы
дәүләт бүләкләрен тапшыру
тәртибе турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләген тапшыру мөмкинлеге чыкмаган бүләкләнүчеләр**
**ИСЕМЛЕГЕ**

______________________________________________ буенча
(Татарстан Республикасы дәүләт органы, җирле үзидарә органы)

| Т/с | Бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (бүләкләнүче муниципаль берәмлекнең, оешманың атамасы) | Бүләкләү турында указның датасы һәм номеры | Бүләкнең төре һәм атамасы | Бүләк тапшырылмауның сәбәпләре* |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

______________________________________________
(исемлеккә кул куйган затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

____________________
(имза)

М.У.

_____ елның «____» __________________

Искәрмә:

* Бүләк тапшырылмауның сәбәпләре: яңа тору урынына күчү (яңа тору урынының адресы); яңа эш урынына күчү (яңа эш урынын күрсәтергә); вафат булу (туганнары булмаса); чит илдә эш сәфәрендә булу (кайту вакыты); гамәлдәге хәрби хезмәткә чакырылу (х/ч урнашкан шәһәр, номеры) һәм башка сәбәпләр.».